**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 21 июнь

№ 418

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 июль, 455 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2014 ел, 7 июль, 455 нче карары белән расланган

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында наркотиклар кулланудан туктаган затларның хезмәт социализациясе проектларын тормышка ашыручы иҗтимагый оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

13 пунктта «һәм заявкаларын бәяләү» сүзләрен «, заявкаларны бәяләү һәм иҗтимагый оешмаларга субсидия бирү турында карарлар кабул итү» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктка түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«Россия Федерациясенең Бюджет кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, алынган акча исәбеннән чит ил валютасын сатып алу субсидия бирүнең субсидия бирү турында шартнамәләргә (килешүләргә) кертелә торган төп шарты булып.»;

22 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидияне максатка яраксыз файдаланган очракта ул максатка яраксыз файдаланылган суммада кире кайтарылырга тиеш.»;

23 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 22 һәм 24 пунктларында күрсәтелгән нигезләр буенча субсидияне кире кайтару вакытларын бозганда Министрлык 22 пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт узган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән җиде көн эчендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару чараларын күрә.»;

24 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«24. Субсидия бирү турында шартнамәләрдә (килешүләрдә) каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше агымдагы финанс елында проектны тормышка ашыру тәмамланган көннән соң 30 көн эчендә, әмма агымдагы финанс елының 1 декабреннән соңга калмыйча субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков